СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 г.Зеленодольск № 72

Зеленодольск шәһәре Советы депутатына карата җаваплылык чараларын куллану турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.1 өлеше, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы ТР Законы, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында»гы ТР Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибендә, 2021 елның 8 декабрендәге 10-11756 номерлыТатарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Идарәсе докладына буенча Дәүләт башлыгының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре буенча

коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча ярдәмчесе Е.С. Ларионовның мәгълүматын тыңлап һәм тикшергәннән соң Зеленодольск шәһәре прокуратурасы тәкъдиме буенча, Коррупциягә каршы тору турындагы законнарны бозган өчен, керемнәр турында дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр биргәндә һәм депутат этикасын бозган өчен, Зеленодольск шәһәре Советы карар чыгарды:

1. 13 нче номерлы бермандатлы сайлау округы буенча дүртенче чакырылыш Зеленодольск шәһәре Советы депутаты Е.В.Ефремовка кисәтү рәвешендә җаваплылык чарасын кулланырга.

2. Зеленодольск шәһәре Советы депутатларына Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә таләпләрен үтәргә тәкъдим итәргә.

3.Карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар кабул ителү вакытыннан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә бастырылып чыгарга тиеш.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**